**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**КӘКРЕ КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

№6 30 октябрь 2025 ел.

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлеге Лесозавод поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы , «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35статьясы ,Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Кәкре Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә КАРАР:

1. 2025 елның 12 ноябрендә 8 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы, Лесозавод бистәсе, Лесозаводская урамы, 9 йорт адресы буенча урнашкан контора бинасында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең Лесозавод бистәсендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлеге Лесозавод поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

**Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүдән гыйбарәт булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан, күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итүгә таләпләр, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Лесозавод бистәсе территориясендә үләннәр чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу).
- Лесозавод бистәсендә урамнарны яктырту җайланмасы (урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

**Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- Лесозавод бистәсендә торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районы рәсми сайтында http://aksubayevo.tatar.ru урнаштырырга һәм рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга .

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Аксубай муниципаль районы
Кәкре Күл авыл җирлеге башлыгы С.С.Елисеев